# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Ак Барс" банкының устав капиталында дәүләт өлешен арттыруга ассигнованиеләрне раслау турында

---

1 статья. "Ак Барс" Акционер коммерция банкы устав капиталында дәүләт (Татарстан Республикасы) өлешен арттыруга Татарстан Республикасының республика бюджетыннан 1550 млн. сум күләмендә ассигнованиеләрне расларга.

2 статья. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнарына, Татарстан Республикасының республика бюджетында берләшкән максатчан бюджет фондларына, дәүләт (республика) предприятиеләренә, учреждениеләренә һәм оешмаларына "Ак Барс" Акционерлар коммерция банкында катнашучылар булырга рөхсәт итәргә.

3 статья. Әлеге Закон матбугатта басылган көненнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 22 декабре
№ 1928